**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.02.2016 № 77

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 22 мартында теркәлде, № 3244

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгында
дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын
биләүче затларның, вазыйфаи бурычларын
үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган
яки китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксынулары барлыкка килүне
хәбәр итүе тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

"Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибе турында, һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 22 декабрендәге № 650 Указына туры китереп, **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибе турындагы кушымта итеп бирелүче нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Дәүләткә хезмәт итү һәм кадрлар бүлегенә: дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән расланган Нигезләмә белән таныштырырга.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары М.Р. Гафаровка йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2016 елның 16 февралендәге № 77 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибе турындагы нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибе турындагы бу нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре), вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибен билгели.

2. Дәүләт хезмәткәрләре, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итә.

Хәбәр язмача, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турындагы хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) рәвешендә, бу Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелә.

3. Хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) дәүләткә хезмәт итү һәм кадрлар бүлегенә тапшырыла.

4. Хәбәрнамә Министрлыкның дәүләткә хезмәт итү һәм кадрлар бүлеге вазыйфаи затлары тарафыннан Хәбәрнамәләрне теркәү журналында (бу Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән) ул кергән көнне теркәлергә тиеш. Хәбәрнамәнең күчермәсе Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тотышына таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә Комиссиянең аны Министрлык тарафыннан расланучы Комиссия турындагы нигезләмәгә туры китереп карап тикшерүен оештыру өчен җибәрелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

______________________________________

____________________________________ дан

(Ф.И.О., биләнүче вазыйфа)

**Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында**

**ХӘБӘРНАМӘ**

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган (кирәклесенең астына сызарга) шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынуым барлыкка килүгә нигез булып торучы шартлар:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Шәхси кызыксынуым аларны үтәүгә тәэсир итә торган вазыйфаи бурычлар:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу яки җайга салу буенча тәкъдим ителүче чаралар:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Бу хәбәрнамәне карап тикшергәндә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тотышына таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга җыенам (җыенмыйм) (кирәклесенең астына сызарга).

"___" ____________ 20___ ел     _______________    ___________________________

(хәбәрнамә җибәргән зат имзасы)     (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килүне хәбәр итүе тәртибе турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турындагы хәбәрнамәләрне теркәү**

**ЖУРНАЛЫ**

| Т/п № | Хәбәрнамәне теркәү номеры | Хәбәрнамәне теркәү көне | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге | Ф.И.О. | имза | Ф.И.О. | имза | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | хәбәрнамәне тапшыручының | | хәбәрнамәне кабул итүченең | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 6 | | 7 | | 8 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |